РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ | КАРАР

№ 21 | 2024 елның 7 мае

«Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлекләренең һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Түбән Кама муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан «Түбән Кама шәһәре» һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль берәмлегенең «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча белдерелгән җирлекләр халкының ризалыгын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» һәм «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә һәм аңа материаллар кертергә.

2.Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән проектны караганда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Р.Х. Муллинны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советы вәкиле итеп билгеләргә.

3. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларының басма басмаларында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында http://e-nkama.ru һәм Прости авыл җирлеге http://prostinskoe-sp.ru/ сайтында басылырга тиеш .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча советның даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.Х. Муллин